СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский",
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGjr.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 3-10

Боерык
«10» июня 2016 года

«Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында»

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131 –ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында; балалар һәм яшьләр проблемаларын хәл итүгә ярдәм итү; социаль әһәмиятле яшьләр инициативасын үстерү; яшьләрнең үсешенә һәм эшчәнлегенә ярдәм итү; яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләргә мәгълүмати-методик консультация бирү; яшьләрнең хокукый культурасы дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итү; муниципаль берәмлек Уставына таянып, Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башкарма комитетына, авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

-балаларның физик, психологик, рухи, социаль, эмоциональ, танып белү һәм мәдәни үсеше өчен кирәкле хокукый, икътисади, социаль-мәдәни һәм башка шартлар тудыру;

- балаларның, шул исәптән авыр тормыш хәлендә булганнарның хокукларына төп гарантияләр бирү;
- яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү;
- яшьләрне эш белән тәэмин итүдә һәм эшкә урнаштыруда катнашу;
- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, балалар һәм яшьләрне сәламәтләндерү буенча ял һәм чаралар оештыру өчен шартлар тудыру;
- балалар һәм яшьләр арасында караучысызлыкны, хокук бозуларны, экстремистик күренешләрне профилактикалау буенча чаралар үткәрү;
- яшь гаиләләргә ярдәм күрсәтү, шул исәптән торак проблемаларын хәл итүдә дә.

2.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә mamadysh.tatarstan.ru.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы В.А.Гыйззәтуллинага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гыйззәтуллина